«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 9 сентябрендәге 679 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Компенсацияне электрон рәвештә бирүне тормышка ашыру максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында»гы 2013 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы (2016 елның 12 маендагы 266 номерлы редакциядә) карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенең 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.8 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«2.8. Компенсация түләүне гамәлгә ашырган җирле үзидарә органы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән социаль ярдәм күрсәтүнең күрсәтелгән чарасын бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә (ары - ЕГИССО) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп.».

2. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов